| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2020 г. г. Альметьевск № 8

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре

(сумнарда )

| «Вазыйфа исеме» | Вазыйфа оклады |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 31 505 |

| | |
|---|---|
| Идарә башлыгы, местәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 21 847 |
| Идарә башлыгы урынбасары, местәкыйль бүлек башлыгы урынбасары (медире), башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 18 282 |
| Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 18 282 |
| Башкарма комитетның идарә составындагы бүлек башлыгы | 18 282 |
| Сектор мөдире | 17 133 |
| Баш белгеч | 16 788 |
| Әйдәп баручы белгеч | 15 753 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 14 603» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә элек чыгарылган хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә.

4. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т.Д. Нагуманов